РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

6 февраль 2019 ел Чистай шәһәре №31/7

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районы Чистай шәһәре
Советының 04.06.2013елгы “Чистай
шәһәрен төзекләндерү Кагыйдәләрен
раслау турында”гы 22/2 нче карарына
үзгәрешләр кертү турында

Чистай шәһәрен төзекләндерү Кагыйдәләрен гамәлдәге закон нигезендә тәртипкә китерү максатында**,** 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 131нче Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы “Чистай шәһәре” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының 04.06.2013 елгы 22/2 нче карары белән расланган (Чистай муниципаль районы Чистай шәһәре Советының 30.04.2014елгы 29/9нчы, 31.08.2017 елгы 17/8нче, 27.06.2018 елгы 26/1нче карарлары редакциясендә) Чистай шәһәрен төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 нче пунктта:

1.1.1. “йорт билгеләре” төшенчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“ күрсәткечләр: - биналар фасадында урнаштырыла торган урамнар исемнәре күрсәткечләр, йортлар, подъездлар һәм фатирлар номерлары, янгын гидрантлары күрсәткечләре, җирдәге геодезик билгеләр, су үткәрү челтәре магистральләре һәм коелары камералары, шәһәр канализациясе, газ үткәргеченең җир астындагы корылмалары күрсәткечләре, объектның инвалидлар өчен файдаланырлык булуы турындагы полигонометрик билгеләр;

1.1.2.” каты көнкүреш калдыклары (ТБО)” төшенчәсеннән “,сабаклар” сүзен алырга;

1.1.3.түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

“архитектур яктырту - кичке вакытта сәнгати-чагылышлы визуаль мохит формалаштыру өчен кулланыла, әлеге Кагыйдәләр белән каралган очракта, шәһәр территориясендә урнашкан аерым гына торучы бинаны яки корылманы, биналар комплексын, мәдәни мирас объектларын,1959 елга кадәрге дата белән төзелгән тарихи биналарны, төзекләндерү элементларын, архитектур-ландшафт объектларын караңгылыкта ачыклап күрсәтү һәм интерпретацияләү;

фасадның архитектур үзенчәлекләре - бинаның аерылып торучы характеристикалары, фасадның, әйләнә-тирәдәге шәһәр төзелеше мохитының конструктив һәм эстетик сыйфаты (стильле һәм композицион тулылык, ритм, туры килүе һәм пропорциональлеге, визуаль кабул ителеше, ачык һәм ябык киңлекләр балансы);

фонсыз конструкции – тышкы мәгълүмат чараларын әзерләү ысулы, бу вакытта конструкция аерым хәрефләрдән, билгеләмәләрдән, билгеләрдән , декоратив элементлардан тора;

витрина – фасад өлешен алып торучы тулысынча пыялаланган төрдәге пыялалы уем (тәрәзә, витраж);

астан яктыртуның эчке ысулы – мәгълүмат конструкциясен астан яктырту ысулы, бу вакытта мәгълүмат кыры аңа юнәлдерелгән читтә урнаштырылган яктылык чыганагы белән яктыртыла;

мәгълүматны тапшыруның динамик ысулы – электрон форма һәм таблодан файдаланып (андагы мәгълүмат алмашып тора) мәгълүмат тапшыру ысулы;

бина - капиталь төзелеш объекты, бердәм күләмдәге төзелеш системасын чагылдыра (төзелеш өчен бер рөхсәт нигезендә төзелгән), ул автоном рәвештә гамәлдә булырга, реконструкцияләнергә һәм файдаланылырга мөмкин;

күпләп йөрү өчен бина, корылма – сәүдә объектлары, административ бина, күпфункцияле үзәкләр, җәмәгать туклануы предприятиеләре, тамашалар объектлары (мәдәни, спорт, театраль, күңел ачу), биналарның гомуми мәйданы 1500 кв. метрдан артып китә;

Чистай шәһәренең тарихи территориясе – аерым шәһәр билгеләнешендәге территория, аларны үзләштерү XI гасыр башыннан 1959 елга кадәр чорга туры килә, аларга карата тышкы мәгълүматны урнаштыру чаралары типлары һәм төрләре, урнаштыруга рөхсәт бирү һәм рөхсәт бирмәү, шул исәптән шундый конструкцияләргә таләпләр, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре), аларны саклау һәм алардан файдалану турындагы Россия Федерациясе законы нигезендә билгеләнгән. Чистай шәһәренең тарихи территориясенең тулай чикләре Чистай шәһәре башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән раслана;

җемелдәүче ут – яктылык динамикалы нәтиҗә, яктылык агымының алмашынуын карый (төс, яктылык, кабыну чираты һ.б.);

барлыкка килгән шәһәр төзелешенең тышкы архитектур йөзен бозу - урнаштыру рөхсәт ителгән һәм рөхсәт ителмәгән тышкы мәгълүматны урнаштыру чаралары тибына һәм төренә карата таләпләрне үтәмәү, шул исәптән шундый конструкцияләрнең тышкы күренешенә һәм урнаштыру

урынына таләпләр, алар Чистай шәһәренең барлыкка килгән төзелешенең тышкы архитектур йөзен саклау зарурлыгын исәпкә алган әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән;

пыяла белән тышланган фасад – тулай пыяладан эшләнгән фасад, фасадның бөтен яссы өслеген яки аның сизелерлек өлешен алып тора;

астан яктыртуның ачык ысулы – мәгълүмат конструкциясен астан яктырту ысулы, бу вакытта яктылык чыганагы аның таралуына каршылык тудырмый;

объектны архитектур яктырту паспорты - билгеләнгән тәртиптә килештерелгән документ, бердәм архитектур-сәнгати яктыртуны билгели, аерым торучы бинаны яки корылмаларны, биналар комплексын, төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектларын, төзекләндерү элементларын, шәһәр террториясендә урнашкан архитектур-ландшафт объектларын бәйрәмнәрдә (вакыйгалар уңаеннан) яктыртуны кертеп;

биналарның һәм корылмаларның, шул исәптән капиталь булмаган, фасадларның колоритлы карарлары паспорты (фасадларның төсләр карары), - билгеләнгән тәртиптә килештерелгән документ, фасадларның бердәм архитектур һәм төс карарларын билгели (фасадлар элементларын кертеп), аның тышкы бизәлешенә таләпләрне билгели;

Чистай шәһәре панорамасы – ачык киңлектән ( яр буе, мәйдан, су объектлары акваториясе, карау мәйданнары) кабул ителүче, шәһәр характеристикасын һәм силуэтын ачучы шәһәр территориясе фрагменты;

Чистай шәһәре урамнары перспективасы – алгы фронтны һәм барлыкка килгән композицияле, стильле һәм сәнгать характеристикалары белән урамнар силуэтын формалаштыручы шәһәр мохиты фрагментын визуаль кабул итү; тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проекты (паспорт) - билгеләнгән формадагы документ, Чистай шәһәре башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән расланган, тышкы күренешне һәм төзекләндерү элементын урнаштыруның төгәл урынын билгели;

яктылык әрҗәсе – тышкы мәгълүмат чарасын ясау ысулы, бу вакытта конструкция бердәй күләмдә булып яки эчке астан яктырту белән күләмле элементлар рәте булып күренә;

тышкы мәгълүматны урнаштыру чарасы (вывеска) – мәгълүмат конструкциясе булып торучы территорияне төзекләндерү элементы, оешма урнашкан урында һәм (яки) турыдан-туры товарны сатуны гамәлгә ашыру, биналарны һәм корылмаларны, шул исәптән капиталь булмаган, мәгълүмати бизәү максатында хезмәт күрсәтү урыннында урнаштырыла, мәгълүматтан файдаланучыларга җиткерү өчен, “Кулланучылар хокукларын яклау турында”гы Федераль законның 9нчы маддәсе көчендә аны күрсәтү мәҗбүри булып тора, бигрәк тә оешманың исеме, аның урнашу урыны (адресы) һәм эш режимы турында мәгълүмат, шулай ук закон көчендә урнаштырылырга тиешле яки гадәти эшлекле әйләнеш көчендә урнаштырыла һәм реклама белән бәйле максатларны күз уңында тотмый торган мәгълүмат. “Тышкы мәгълүматны урнаштыру чарасы” һәм “тышкы мәгълүмат чарасы” төшенчәләре тәңгәл;

аерым шәһәр билгеләнешендәге территория – Чистай шәһәре территориясенең аерым статуска һәм (яки) югары мәдәни-рекреацион һәм

социаль кыйммәткә ия булган өлешләре, аларга карата барлыкка килгән Чистай шәһәре төзелешенең тышкы архитектур йөзен саклау максатында әлеге Кагыйдәләр нигезендә тышкы мәгълүматны урнаштыру чарасының тибы һәм төрләре, урнаштыруга рөхсәт бирү һәм рөхсәт бирмәү белән, шул исәптән шундый конструкцияләргә таләпләр билгеләнә.

фонлы конструкцияләр - тышкы мәгълүмат чарасын ясау ысулы, бу вакытта хәрефләр, билгеләр һәм декоратив элементлар фон өслегендә урнаштырыла;

фриз – горизонталь полоса төрендә фасадны яки козырекны декоратив кысага алган элемент;

фронтон – бина фасадының төгәлләүче өлеше, түбә дәрәҗәсеннән өстәрәк чыгып тора, тәрәзәләрнең иң югары билгесеннән соңгы катка кадәр яки фасадның чыгып тора торган элементының иң югары билгесенә кадәр үлчәнә.”;

1.2. “Йорт билгеләре” бүлекчәсенең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: "Күрсәткечләр".

1.3. 31 – 39 нчы пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“31. Биналар, корылмалар фасадлар күрсәткечләр белән җиһазландырылырга тиеш.

32. Урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәтчкечләр Чистай шәһәре башкарма комитетының муниципаль хокукый акты, әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән урыннарда урнаштырыла һәм үтәлә.

33. Биналарда, корылмаларда, тарихи территория чикләрендә, шулай ук фасадлары белән шәһәр мохиты эстетикасына югары таләпләр булган урамга һәм гомумшәһәр юлларына чыгучы биналарда урнаштырылган урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләрдәге мәгълүмат Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә урнаштырыла. Урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләр типларына һәм төрләренә бердәм нормага китерүче таләпләр Чистай шәһәре башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән билгеләнә.

34. Фасадларда урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәтчкечләр түбәндәге урыннарда урнаштырыла:

-җир өслегеннән 2,5 м.дан түбән һәм 5,0 м.дан югары булмаган биеклектә;

- фасадның тышкы почмагыннан 1,0 м.дан артык түгел;

- витрина, тәрәзә пыялаларын, архитектур детальләрне һәм декоратив-сәнгать бизәлешен капларга тиеш түгел;

- яктыртуның ачык ысулыннан файдаланмыйча;

- фасадның архитектур үзенчәлекләрен исәпкә алып;

-төп һәм ян фасадта – фасадның уң ягыннан, әлеге Кагыйдәләр белән каралган очраклардан кала;

- ишек алдындагы фасадта – кварталлар буйлап йөрү ягыннан;

- транспорт бер яклы гына хәрәкәт итүче урамнарда – транспорт хәрәкәте буенча иң якын фасад ягында;

- сәнәгать предприятиеләре коймаларында һәм корпусларда – төп керү юлының уң ягында;

- фасадлары урамнар чатына һәм гомумшәһәр юлларына чыгып торучы биналарда – урам чатыннан иң якын фасад почмагында;

- бердәм горизонталь һәм вертикаль үзәкне исәпкә алып.

35.Аерым торучы күрсәткечләр (стела) урнаштыру рөхсәт ителми:

- нейтраль төсләрдән (соры, кара, коңгырт һәм башка караңгы төсләр) һәм (яки) табигый материаллардан эшләнмәгән;

- биеклеге 6,0 м.дан артыграк булса;

- нигезне тирәнәйтмичә;

-урнаштыру тротуарның норматив киңлеген тарайтуга китергән очракларда, шулай ук, автомобильләр туктап тору өчен билгеләнгән урыннарда, керү юлларында;

- төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектларын, мәдәният объектларын, Чистай шәһәре панорамаларын һәм перспективаларын кабул итүне чикләүче;

- агач кәүсәләреннән 5,0 м якын аралыгында эчкә төшкән нигез булган урыннарда, объект проекты белән каралган җир участогы чикләрендә яшел үсентеләр (агачлар, куаклар) урынына;

- ясаганда профнастилдан, тукыма материаллардан, ныгытуның ачык ысулыннан файдаланып;

- мәгълүмат кырында фоторәсемнәр белән;

- мәгълүмат тапшыруның динамик ысулыннан файдаланып, парковка урыннары саны турындагы мәгълүматтан кала.

36. Аларда подъездлар һәм фатирлар номерларын күрсәткечләр ишек уемнары өстенә яки ишек уемыннан уң якта 2,0 - 2,5 м. биеклектә урнаштырыла.

37. Янгын сүндерү гидрантлары, полигонометрик билгеләр урнашкан күрсәткечләр, геодезик билгеләрнең урнашу урыны күрсәткечләре биналарның тышка чыгып торган аскы өлешендә, су үткәрү һәм канализация челтәре магистральләре һәм коелары камераларында урнаштырыла.

38. Янгын сүндерү гидрантлары, полигонометрик билгеләр урнашкан күрсәткечләр, геодезик билгеләрнең урнашу урыны күрсәткечләрен урамнар, йорт номерлары күрсәткечләре белән янәшә урнаштыру, шулай ук аларны архитектур детальләрдә, декоратив-сәнгать бизәлешләрендә, пыялада, капкаларда, ишекләрдә урнаштыру рөхсәт ителми.

39. Күрсәткечләрне чиста итеп һәм төзек хәлдә тотарга кирәк.”.

1.4. 40 - 42 нче пунктларны алып ташларга;

1.5. 75нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“75. Урамнар, юллар, мәйданнар, җәяүлеләр тротуарлары, торак кварталлар, ишек аллары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар территорияләре, шулай ук урамнар исемнәре һәм йортлар номерлары күрсәткечләре, юл билгеләре һәм күрсәткечләре, тышкы мәгълүмат чаралары һәм витриналар тәүлекнең караңгы вакытында яктыртылырга тиеш.

Урамнарны, юлларны, мәйданнарны, микрорайоннар территорияләрен тышкы яктырту табигый яктылык кимегәч 20 лк.га кадәр кичке эңгер-меңгердә кабына, ә иртәнге якта 10 лк.га кадәр күтәрелгәндә сүнә.

Торак йортлар подъездларын, урамнар исемнәре һәм йортлар номерлары күрсәткечләре, архитектур яктырту системаларын, тышкы мәгълүмат чараларын тышкы яктырту җайланмаларын кабызу һәм сүндерү урамнарны тышкы яктырту эше режимында башкарыла.”;

1.6. _195нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“195. Төзекләндерүнең түбәндәге элементлары билгеләнгән тәртиптә килештерелгән проект (паспорт) нигезендә урнаштырыла һәм аның белән тулысынча туры китереп:

- аерым торучы күрсәткечләр (стелалар);
- тышкы мәгълүмат чаралары;
- декоратив-сәнгать бизәлеше төрендәге кече архитектура формалары, мобиль һәм вертикаль яшелләндерүне башкару өчен җайланмалар, судагы корылмалар, типовой муниципаль мебель, коммуналь-көнкүреш җиһазлары;
- капиталь булмаган объектлар, шул исәптән шәхси башкарылган сезонлы объектлар һәм стационар булмаган сәүдә объектлары;
- биналарны, корылмаларны, шул исәптән капиталь булмаган биналарны, корылмаларны архитектур яктырту, аерым витриналардан кала;
- фасадларның төсләр чишелеше, шул исәптән декоратив-сәнгать бизәлеше төрендә;
- гомуми куллану, куллану чикләнгән территорияләрне комплекслы төзекләндерү;
- кондиционерларның тышкы блокларын комплекслы урнаштыру.

Мәдәни мирас объектларын саклау зоналарында урнашкан территорияне төзекләндерү элементларына проект (паспорт) мәдәни мирас объектларын саклау, файдалану, популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә вәкаләтләре булган органнар белән килештерелә.

Озак сроклы яки даими файдаланудагы территорияне төзекләндерүнең стационар элементлары аларны кул белән күчерү мөмкинлеге юкка чыгарырлык итеп ныгытыла.

Төзекләндерү элементларындагы мәгълүмат Россия Федерациясенең дәүләт теле һәм Татарстан Республикасының дәүләт телләре турындагы законнар таләпләрен үтәп урнаштырыла.

Ике яки берничә телдән файдаланган очракта текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча тәңгәл килергә, төгәл үтәлергә тиеш.”.

1.7. “Тышкы реклама һәм мәгълүмат чаралары” бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“227. Тышкы реклама һәм мәгълүматны урнаштыру чаралары техник яктан төзек һәм эстетика белән каралган булырга тиеш.

Тышкы мәгълүмат чаралары, учреждение такталары һәм эш режимы табличкаларыннан кала, вәкаләтле орган белән килештерелгән паспорт нигезендә һәм тулысынча аңа туры китереп урнаштырыла һәм файдаланыла.

Тышкы реклама һәм мәгълүматны урнаштыру чаралары хуҗалары аларның тиешле тәртиптә булуын тәэмин итәләр, аларны үзвакытында ремонтлыйлар һәм тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру урыннарын чистарталар.

Тышкы реклама һәм мәгълүматны урнаштыру чараларын аларга реклама яки мәгълүмат урнаштырмыйча гына урнаштыру һәм файдалану, мәгълүмат кырына зыян китерү, тышкы реклама һәм мәгълүмат чаралары өстенә башка нәрсә элү, аларга полиэтилен пленка яки башка материал ябыштыру рөхсәт ителми.

Реклама яки мәгълүмат конструкциясе хуҗасы монтажлаганнан соң (сүтеп алганнан соң) өч тәүлек эчендә территорияне һәм (яки) фасадның тышкы күренешен төзекләндерә.

Тышкы реклама һәм мәгълүматны урнаштыру чаралары нигез блокларында булган очракта нигез блогы белән бергә сүтелергә тиеш.

Корылмаларга һәм объект өлешләренә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын ныгытып урнаштырганда аларга зыян китерү, шулай ук аларның тулылыгын, ныклыгын киметү рөхсәт ителми.

Тышкы реклама һәм мәгълүматны урнаштыру чараларын тиешле тәртиптә тотмаган, ул урнашкан җир участогын һәм аның янындагы территорияне җыештыру һәм санитар карап тоту өчен тышкы реклама һәм мәгълүматны урнаштыру чаралары хуҗалары җаваплы.

227.1. Реклама конструкцияләренең тышкы күренешенә һәм урнаштыру урынына таләпләр Чистай шәһәре башкарма комитетының “Чистай шәһәрендә реклама конструкцияләрен урнаштыру турында”гы норматив-хокукый акты белән билгеләнә.

227.2 Тышкы мәгълүматны урнаштыру чаралары түбәндәге төрләрдә булырга мөмкин:

- дивар конструкциясе;
- декоратив панно;
- консольле конструкция;
- түбә конструкциясе;
- витрина конструкциясе;
- учреждение тактасы;
- режим табличкасы;
- модульле конструкция;
- күләмле-киңлекле композиция;
- щит конструкциясе;
- эләмнәр композициясе;
- махсус конструкция.

227.3. Тышкы мәгълүматны урнаштыру чараларына гомуми таләпләр.

227.3.1. Тышкы мәгълүматны урнаштыру чараларын проектлаштыру, ясау һәм урнаштыру төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре таләпләре, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре), аларны саклау һәм алардан файдалану турындагы Россия Федерациясе законы нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш.

227.3.2. Тышкы мәгълүмат чаралары типовой һәм шәхси үтәлеп урнаштырылырга мөмкин.

Ике яки берничә телдән файдаланган очракта текстлар эчтәлеге һәм техник бизәлеше буенча тәңгәл килергә, төгәл һәм грамоталы үтәлергә тиеш.

227.3.3. Мәгълүмат конструкциясе иясе теләсә нинди иминлек кагыйдәләрен бозган, шулай ук мәгълүмат конструкцияләрен монтажлау һәм файдалану шартларын бозганда төзексезлекләр һәм аварияле хәлләр өчен җавап тота.

227.3.4. Тышкы мәгълүматны чараларын урнаштыру рөхсәт ителми:

1) күп фатирлы торак йортлар фасадларында:

- торак биналар чикләрендә, турыдан-туры торак булмаган бина алып торган, беренче һәм икенче катлар арасында урнаштырылган конструкцияләрдән кала;

- эчендә төзелгән торак булмаган биналар чикләрендә, чыгып тору чиге 1,5 м.дан артык булмаган торак йорт габаритларында урнашкан һәм мәгълүмат конструкциясен урнаштырган зат алып торган, турыдан-туры торак булмаган бина алып торган, беренче һәм икенче катлар арасында урнаштырылган конструкцияләрдән кала;

- тәрәзә һәм ишек уемнарын, шулай ук витражларны һәм витриналарны, шул исәптән өстәп-ялгап төзелгән биналардагы, тулысынча яки өлешләп каплау төрендә, әлеге Кагыйдәләр белән каралган очраклардан кала;

- лоджийлар, балконнар кырыйларындагы конструкцияләрдә, әгәр ул ишек проекты тәкъдиме белән каралмаган булса;

- бер керү урыны белән бердән артык конструкция;

2) торак булмаган билгеләнештәге биналар фасадларында:

- биш каттан күбрәк биеклектәге биналарда вертикаль консоль конструкцияләр;

- икенче кат тәрәзәсенең аскы дәрәҗәсеннән югары, әлеге Кагыйдәләр белән каралган очраклардан кала;

3) керү төркемнәре фризларында, козырекларда:

- бер керү урыны белән бердән артык конструкция;

- яктылык әрҗәләре, фонлы конструкцияләр төрендә - бер керү урыны булган керү төркеме фризында урнаштырылганнардан кала;

4) төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектларын, мәдәният объектларында:

- фонлы конструкцияләр, яктылык әрҗәләре, динамик конструкцияләр, витрина һәм консольле конструкцияләр, декоратив паннолардан кала;

- җемелдәп торучы уттан файдаланып;

- архитектур фон белән туры килмәүче контрастлы һәм тулы төсләр чишелешендә;

5) гомуми мәйданы 400 кв. м.дан артыграк булган административ-офис, сәүдә, мәдәни-күңел ачу спорт объектларында, шундый объект проекты белән каралмаган;

6) шәхси һәм күп фатирлы торак йортлар территорияләрендә аерым торучы конструкцияләр төрендә;

7) биналардагы уемнарны, витрина пыялаларын, тәрәзәләрне, аркаларны, архитектур детальләрне һәм декоратив-сәнгать бизәлешен, суперграфиканы тулысынча һәм яртылаш каплаучы, әлеге Кагыйдәләр белән каралган очраклардан кала;

8) фасадның архитектур үзенчәлекләрен исәпкә алмыйча. Биналар фасадларында тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру вариантлары әлеге Кагыйдәләргә кушымталар нигезендә билгеләнә;

9) эркерларда, колонналарда, пилястрларда, балконнарда;

10) мемориаль тактадан 2,0 м.дан якынрак аралыкта;

11) адреслы атрибутиканы каплап торучы (урамнар исемнәре һәм йорт номерлары күрсәткечләре);

12) 2 каттан артыграк биеклектәге биналарның ябык торецларында;

13) мәгълүматны алмаштырып, декоратив паннодан кала, модульле конструкцияләр, шулай ук ягулык салу станцияләрендәге күләмле-киңлекле композицияләрдән, банк операцияләрен гамәлгә ашыручы оешмалар өчен щитлардан, витриналардан, консольле конструкцияләрдән кала;

14) мәгълүмат кырының гомуми мәйданыннан 10% артыграк булган “Куллнучылар хокукын яклау турында”гы Федераль законның 9нчы маддәсе көчендә (оешманың исеме, аның урнашу урыны (адресы) һәм эш режимы турында мәгълүмат) мәҗбүри булмаган мәгълүматны күрсәтү, бигрәк тә юнәлешләрне билгеләү, товарлар һәм хезмәтләр исемлеге, биналарны арендага бирү, сату турында мәгълүмат, модульле конструкцияләр, щит һәм витрина конструкцияләре төрендәге коймалардагы һәм биналардагы эленмәләрдән кала;

15) текстлы мәгълүматтан кала бары тик рәсемнән генә торучы;

16) төсе буенча фасадның архитектур фоны белән туры килми;

17) астан яктыртуның ачык ысулыннан файдаланып;

18) ясаганда тукыма материаллар кулланып, әләмнәр композициясеннән, шулай ук 6,0 м.дан артыграк булган озынлыктагы яктылык әрҗәләре төрендәге дивар конструкцияләреннән кала;

19) бер төрдәге мәгълүмат конструкциясеннән файдаланып мәгълүматны кабатлау, түбәндәгеләрдән кала:

- мәгълүмат Россия Федерациясенең дәүләт теле һәм Татарстан Республикасының дәүләт телләре турындагы законнар таләпләрен үтәп эшләнгән;

- берничә урам чатында яки ике урам арасындагы территориядә урнашкан бина фасадларының һәрберсендә урнаштырылучы мәгълүмат;

-ягулык салу станцияләре фасадларында урнаштырылучы мәгълүмат;

20) кабартыла торган конструкцияләр, штендерлар төрендә;

21) өстәп-ялгап төзелгән бина түбәсенең (парапет, фриз) иң югары тамгасыннан биегрәк, (тамбурларны да кертеп);

22) Чистай шәһәренең тарихи мәйданнары чикләрендә җемелдәүче уттан файдаланып;

23) телефон номерларын, сайтларны, электрон почта адресларын күрсәтеп.

227.3.4.1. Тышкы мәгълүмат чаралары урнашкан урыннарда бина фасады үзгәргәндә тышкы мәгълүмат чаралары сүтелергә тиеш, түбәндәге очракларда:

-фасадның тышкы күренешен үзгәртү белән бәйле рәвештә бинаның катлары саны артканда;

- фасадның тышкы күренешен үзгәртү белән бәйле рәвештә катлар биеклеген арттырганда яки киметкәндә;

-фасадның төсләр чишелешен үзгәртү, суперграфика белән каралган;

- фасадта уемнар габаритларын арттыру;

- төзелешләр мәйданнарын, өстәп-ялгап төзелгән объектларны (капиталь, капиталь булмаган) арттыру;

- фасадның архитектур үзенчәлекләрен үзгәртү, шул исәптән архитектур детальләр, декоратив-сәнгати бизәлеш, ишекләр козыреклары җайланмалары урнаштыру.

227.4. Тышкы мәгълүматны урнаштыру чараларының аерым төрләренә таләпләр:

227.4.1. Дивар конструкциясе - мәгълүмат конструкциясе, диварларның, фризларның, козырекларның, бина фронтоннарының тышкы өслекләрендә, стационар булмаган сәүдә объектларының ишекләре яки тәрәзәләре (витриналар) өсләрендә, тәрәзәләр арасында дивар өслегеннән 0,2м.дан артыграк булмаган аралыкта, фонлы яки фонсыз конструкцияләр, яктылык әрҗәләре төрендә урнаштырыла, ул ныгыту элементларыннан, текстлы мәгълүматы, декоратив элементлары һәм (яки) билгеләре, яисә турыдан-туры дивар өслегенә ясалган рәсеме булган мәгълүмат кырыннан тора.

Дивар конструкцияләрен урнаштыру рөхсәт ителми:

1) бина, стационар булмаган сәүдә объекты катлары тәрәзәләре арасындагы аралык биеклегеннән 2/3тән артыграк биеклектә;

2) арка тәрәзәләре булганда бина, стационар булмаган объект катлары тәрәзәләре арасындагы аралык биеклегеннән 1/2дән артыграк биеклектә;

3) фриз биеклегеннән 2/3тән артыграк текст мәгълүматы биеклегендә;

4) бер катлы биналардагы (шул исәптән өстәп-ялгап төзелгән биналардагы) , ишекләрдәге, стационар булмаган сәүдә объектларындагы фриз биеклегеннән кимрәк яки артыграк булган озынлыктагы фризларда урнаштырыла торган яктылык әрҗәләре, фонлы конструкцияләр төрендә;

5) бина, стационар булмаган сәүдә объекты фронтоны биеклегеннән 1/2дән артыграк биеклектә;

6) козыректа 0,5 м.дан артыграк биеклектә;

7) фасад озынлыгыннан 70%нан артыграк озынлыкта;

8) беренче кат чикләрендә уемнар арасында урнаштырганда 0,5 м.дан артыграк биеклектә, 50%тан артыграк озынлыктагы аралыкта һәм почмактагы участокларда 1,5 м.дан артыграк биеклектә, 50%тан артыграк озынлыктагы аралыкта;

9) башка телләрдәге мәгълүматтан файдаланганда әлеге Кагыйдәләр белән билгеләнгән конструкция озынлыгыннан 50%тан артыгракка артырылган озынлыкта;

10) төрле телләрдәге күләмнәре һәм шрифтлары тәңгәл килмәгән язулар кулланып;

11) беренче, цоколь яки подвал катларындагы тышкы дивар өслегенә урнаштырганда җир тигезлегеннән алып дивар конструкциясенең аскы кырыена кадәр 0,6 м.дан астарак;

12) уемнар булганда, тулай пыяла, фриз, фронтон булмаганда икенче каттан биегерәк, конструкцияне урнаштыру күз алдында тотылган ике тәрәзә уемы биеклегенннән артып киткән очраклардан кала;

13) икенче каттан биегерәк тулай пыялада урнаштырганда бердән артыграк сандагы конструкция;

14) тарихи территория чикләрендә урамга карап тора торган бина, стационар булмаган сәүдә объектының ( элеге урамнар корылмаларының алгы линиясен формалаштыра) төп һәм ян-як фасадларында фонлы конструкция һәм яктылык әрҗәсе төрендә, шәһәр мохиты эстетикасына күтәренке таләпләр белән Чистай шәһәре урамнары һәм гомумшәһәр юллары буйлап, автомобильләр сату буенча махсус объектлардан кала;

15) бер-берсе өстендәге фонлы конструкцияләр һәм яктылык әрҗәләре төрендә, элеге Кагыйдәләр белән каралган очраклардан кала;

16) фриздагы фонлы конструкцияләр һәм яктылык әрҗәләре төрендә, аның өслеге бина, стационар булмаган сәүдә объекты диварларына, керү ишекләренә, козырекларга параллель урнашмаган;

17) бинада, стационар булмаган сәүдә объектында фонлы конструкцияләр фоны төсеннән файдаланып, фриз төсеннән аерыла;

18) беренче кат яки беренче каттан астарак булган уемнар арасында урнаштырганда фонлы конструкцияләр һәм яктылык әрҗәләре;

19) мәгълүматны алмаштырып;

20) рәсем белән, турыдан-туры дивар конструкцияләренең башка төрләреннән файдалану күз уңында тотылган биналар фасадларында дивар өслегенә төшерелгән;

21) мәгълүматны тапшыруның динамик ысулыннан файдаланып;

22) түбә конструкциясе булганда югары катның фронтонда, фризында элеге бинада конструкция урнаштыру каралган урын өстендә урнаштырылган, ул рөхсәт (килешү) нигезендә урнаштырылган, гамәлдә булу срогы чыкмаган, бердәм мәгълүматлы эчтәлектәге дивар конструкциясе белән берләштерелгән түбә конструкциясеннән кала (бер эшчәнлек турында уртак мәгълүмат);

23) төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектларында 0,5 м.дан артыграк биеклектә;

24) Чистай шәһәренең тарихи территориясе чикләрендә 1,0 м.дан артыграк биеклектә;

25) бина, стационар булмаган сәүдә объекты диварыннан түбәне аерып торучы кәрниз тигезлегеннән югарырак, кәрниз тигезлегеннән скатлы түбә сыртына кадәр 3,0 м.дан кимрәк биеклек булганда;

26) бина, стационар булмаган сәүдә объекты диварыннан түбәне аерып торучы кәрниз тигезлегеннән югарырак бердән артыграк сандагы конструкция;

27) вертикаль тәртиптә:

- биш каттан түбәнрәк бинага урнаштырганда;
- яктырту әрҗәләре һәм фонлы конструкцияләр төрендә;
- бинада бердән артыграк;
- 3 м.дан кимрәк киңлектәге аралыкта;
- 3м.дан кимрәк биеклектәге;

- бер яки күбрәк багана;

- түбә конструкциясе булганда;

- бинаның, корылманың гомуми исемен чагылдырмаганда;

28) бинаның гомуми исемен чагылдырмаучы, гомуми мәйданы 400,0 кв. м.дан кимрәк булган бина, корылма, шул исәптән капиталь булмаган, фасады (фриз, фронтон) төгәлләнгән урында бердән артыграк;

29) 0,3 м.дан артыграк биеклектәге цоколь һәм подвал катларының тышкы дивары чикләрендә.

227.4.2. Декоратив панно - мәгълүмат конструкциясе, бары тик аерым торучы, гомуми мәйданы 1500 кв. м.дан артыграк булган сәүдә-офис, мәдәни-күңел ачу, производство, склад һәм спорт билгеләнешендәге объектлар фасадларында гына урнаштырыла. Әлеге конструкциянең мәгълүмат кыры каты яки тукымалы нигездә эшләнгән булырга тиеш, мәгълүмат кырын һәм каркасны тоташтыручы урын яшерелгән, ә кырыйлары декоратив бизәлгән булырга тиеш (шул исәптән багет, сәнгать декоры элементлары).

Декоратив панно урнаштыру рөхсәт ителми:

1) беренче кат дәрәҗәсеннән астарак;

2) төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектларында;

3) тарихи территорияләр чикләрендә, аерым торучы мәдәни-күңел ачу, спорт билгеләнешендәге объектлар фасадларында, алар уздырыла торган чаралар турында мәгълүмат урнаштыру өчен билгеләнгән;

4) ишекләр һәм тәрәләр уемнары арасында, витринадан кала;

5) эчке яктан яктыртмыйча гына баннерлы тукыма кулланып;

6) мәгълүматны тапшыруның динамик ысулыннан файдаланып;

7) тарихи территорияләр чикләрендә җир участогы чикләрендә аерым торучы щит конструкцияләре булганда яки шундый конструкцияне урнаштыру мөмкинлеге булганда.

227.4.3. Консольле конструкция - мәгълүмат конструкциясе, бина, стационар булмаган сәүдә объекты фасады яссылыгына туры почмак итеп, почмаклы участокларда кече конструкцияләр төрендә диварның тышкы өслегенең композицион үзәкләре буенча урнаштырыла.

Консольле конструкция урнаштыру рөхсәт ителми:

1) 1,0 м.дан артыграк биеклектә һәм озынлыкта;

2) төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектларында 0,5 м.дан артыграк биеклектә һәм озынлыкта;

3) фасад өслегеннән 0,2 м.дан артыграк арада;

4) бер-берсеннән 10м.дан якынрак арада;

5) фасад кырыеннан 0,2 м.дан артыграк һәм җир өслегеннән конструкциянең аскы кырыена кадәр 2,5 м.дан кимрәк арада;

6) турыдан-туры бина ишекләре өстендә;

7) вертикаль хәлдәге – тарихи террритория чикләрендә урамга карап торучы биналар фасадларында ( әлеге урамнардагы корылмаларның алгы линиясен формалаштыра);

8) төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектларында металл декордан файдаланмыйча;

9) мәгълүматны тапшыруның динамик ысулыннан файдаланып, банк операцияләрен гамәлгә ашыручы биналар өчен консольле конструкцияләрдән кала.

227.4.4. Түбә конструкциясе – эчтән яктыртылган янып торучы хәрефләр һәм символлар (логотиплар, саннар, билгеләр, сәнгать элементлары) төрендәге күләмле мәгълүмат конструкциясе, ул әлеге бинаның гомуми мәйданының 100%тан артыгын алып торучы оешма тарафыннан, бинаның, стационар булмаган сәүдә объектының тигез түбәсенең (парапет) яки скатлы түбәнең югарыгы билгесеннән биегрәк урнаштырыла.

Түбә конструкцияләрен урнаштыру рөхсәт ителми:

1) текстлы мәгълүмат биеклегендә:

- 0,5 м.дан артыграк - бер катлы биналар, стационар булмаган сәүдә объектлары өчен;

- 2,0 м.дан артыграк - 2 - 5-катлы биналар өчен;

- биеклек буенча чикләүләрсез – төзелеш мәйданы 15 мең кв.м.дан артыграк булган эре сәүдә үзәкләре биналары өчен;

2) озынлыкта:

- фасадның туп-туры төгәлләнгән урынында 1/2гә артыграк озынлыкта;

- фасадны төгәлләүче өлешнең (парапет) биеклеген киметкәндә төгәлләү фрагменты озынлыгыннан 2/3кә артыграк;

3) Чистай шәһәренең тарихи территорияләре чикләрендә урнашкан, төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектларын, мәдәният объектларында;

4) төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектларын, мәдәният объектларын, Чистай шәһәре панорамаларын һәм перспективаларын кабул итүне чикләүче;

5) күп фатирлы торак биналарда;

6) бинада, стационар булмаган сәүдә объектында бердән артыграк, Россия Федерациясенең дәүләт теле һәм Татарстан Республикасының дәүләт телләре турындагы законнар таләпләрен үтәп эшләнгән, мәгълүматны кабатлаучы конструкциядән кала;

7) әлеге бинада рөхсәт (килешү) нигезендә урнаштырылган, гамәлдә булу срогы чыкмаган, түбә җайланмасы төрендәге реклама конструкциясе булганда;

8) әлеге бинада рөхсәт (килешү) нигезендә урнаштырылган, гамәлдә булу срогы чыкмаган югары кат фронтонында, фризында вертикаль тәртиптәге дивар конструкциясе булганда, бер төрле мәгълүматлы эчтәлектәге түбә конструкциясе белән берләштерелгән дивар конструкциясеннән кала;

9) мәгълүматны алмаштырып;

10 мәгълүматны тапшыруның динамик ысулыннан файдаланып;

11) текстлы мәгълүматтан 1/3тән артыграк биеклектәге өстәмә символлар биеклегендә (логотиплар, саннар, билгеләр, сәнгать элементлары)

227.4.5. Витрина конструкциясе - фонлы конструкция яки яктылык әрҗәләре төрендәге мәгълүмат конструкциясе, бинада, стационар булмаган

сәүдә объектында витрина пыяласының, тәрәзә уемының эчке ягыннан урнаштырыла, каркастан, декоратив-бизәлеш кырыйлы мәгълүмат кырыннан, эленмә элементлардан тора, тәрәзә уемы мәйданының 1/4 тан артык булмаган өлешен алып тора.

Витрина конструкцияләрен урнаштыру рөхсәт ителми:

1) 2,0 кв. м мәйданнан кимрәк булган тәрәзә уемында;

2) витрина пыяласыннан витрина конструкциясенә кадәр бина ягыннан 0,15 м кимрәк булган арада;

3) тәрәзә рамы кисәкләрен исәпкә алмыйча;

4) витрина пыяласы өслегеннән буяу һәм декоратив пленкалар белән каплау төрендә;

5) витрина пыяласын яктылык әрҗәләренә алмаштыру юлы белән;

6) мәгълүматны тапшыруның динамик ысулыннан файдаланып;

7) витрина конструкцияләре арасында 1,5 м.дан кимрәк ара.

227.4.6. Учреждение тактасы, режим табличкасы – мәгълүматны кулланучылар игътибарына җиткерү өчен билгеләнгән мәгълүмат конструкцияләре, аны күрсәтү “Кулланучылар хокукын яклау турында”гы Федераль законның 9 нчы маддәсе нигезендә мәҗбүри булып тора, оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә оешманың, шәхси эшмәкәрнең исеме, аның урнашу урыны (адресы) һәм эш режимы турында, биналарда, стационар булмаган сәүдә объектында яки коймада төп ишектән уң һәм (яки) сул яисә турыдан-туры ишек пыяласына урнаштырыла (режим табличкасы).

Учреждение тактасында, режим табличкасында урнаштырыла торган мәгълүмат кулланучыларга Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә дә җиткерелергә тиеш.

Учреждение тактасын, режим табличкасын урнаштыру рөхсәт ителми:

1) 0,6 м.дан артыграк озынлыктагы һәм 0,8 м.дан артыграк биеклектәге (учреждение тактасы);

2) 0,4 м.дан артыграк озынлыктагы һәм 0,6 м.дан артыграк биеклектәге (режим табличкасы);

3) 0,6 м.дан артыграк озынлыктагы һәм 0,4 м.дан артыграк биеклектәге (режим табличкасы, трафаретлы басу ысулы белән ишек пыялаларына урнаштырыла);

4) оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә эшләүче бер оешма, бер шәхси эшмәкәр бер бинада, стационар булмаган объектта, коймада;

5) күләмнәре белән аерылып торучы, конструкция ясалган материал буенча тәңгәл килми;

6) ишекләрнең пыялалы өлешендә бердән артыграк, трафаретлы басу ысулы белән эшләнгән;

7) астан яктыртуны файдаланып, коймалардагы эленмәләрдән кала;

8) фонсыз конструкцияләр төрендә;

9) ишекнең бер ягында икедән артык;

10) койма секцияләре янында;

11) төзелеш коймаларында, баскычлар, балконнар, лоджийлар кырыйларында;

12) стационар җәмәгать туклануы предприятиеләре каршындагы сезонлы кафелар коймаларындагы конструкцияләрдә;

13) тарихи территорияләр чикләрендә урнашкан, төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектлары, мәдәният объектлары коймаларында, әлеге урамнардагы төзелешләрнең алгы линиясен формалаштыра;

14) койма тигезлегеннән югары;

15) мәгълүматны тапшыруның динамик ысулыннан файдаланып.

227.4.7. Модульле конструкция – ул эленмәнең төрлелеге, оештыру-хокукый формасына бәйсез рәвештә бер бинада берничә оешма, шәхси эшмәкәр урнашканда бердәм блокка берләштерелгән модуль төрендә файдаланыла, бинага, шундый бина коймасында яки ул урнашкан җир участогында яки бинадан файдалану өчен яки автомобильләрнең туктау урынын оештыру итеп бирелгән участок белән чиктәш җир участогына урнаштырыла.

Модульле конструкция түбәндәге төрләрдә урнаштырылырга мөмкин:

- декоратив панно;

- консольле конструкция;

- эленмәләр, режим табличкалары, турыдан-туры ишек пыяласында эшләнгәннәрдән кала;

- эре форматтагы күләмле-киңлектәге композицияләр.

Модульле конструкцияләргә әлеге пункт белән каралган үзенчәлекләрне үтәгәндә мәгълүмат конструкциясенең тиешле төре өчен билгеләнгән таләпләр тарала.

Модульле конструкцияләрне урнаштыру рөхсәт ителми:

1) биеклеге 6,0 м артыграк һәм 2,0 м дан азрак (консоль конструкцияләр);

2) тарихи территорияләр чикләрендә урамга чыгып тора торган биналар (әлеге урамнардагы корылмаларның алгы линиясен формалаштыра) фасадларында (консольле конструкцияләр);

3) биш каттан да артыграк биеклектәге биналарда (консольле конструкцияләр);

4) күп фатирлы торак йортлар фасадларында, ялгап-өстәп төзелгән биналардан кала на (консольле конструкцияләр);

5) төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектларында (консольле конструкцияләр);

6) модульле элементларның мәгълүмат кырын төрле материаллар файдаланып әзерләү һәм бер үк блокта һәм бер үк бинада астан яктырту ысуллары;

7) бер конструкциядә өч модульле элементтан торган санда;

8) декоратив панно төрендә модульле конструкция булганда консольле;

9) кронштейн төрендә модульле конструкция булганда декоратив панно төрендә;

10) бер конструкция төрендә бер бинада икедән артыграк блок;

11) биеклеге һәм озынлыгы 1,5 мдан артыграк (учреждение тактасы, режим табличкасы);

12) урнашкан стена озынлыгыннан 2/3 артыграк озынлыкта (учреждение тактасы, режим табличкасы);

13) ишектән чыгуның бер ягында бердән артыграк (учреждение тактасы, режим табличкасы).

227.4.8. Күләмле – киңлектәге композиция – аерым торучы декоратив-мәгълүмати конструкция, кече (6,0 м дан биек түгел) яки эре (6,0 м дан артыграк) форматта шәхси үтәлеп башкарылган, нигездән, каркастан торучы, нейтраль төстәге материаль белән тышланган (соры, көрән, графит, кара, коңгырт, һ.б.), оешманың фирма исеме турында кычкаса гына мәгълүматлы, ә күпләп йөри торган биналар, корылмалар өчен 1500 кв. м дан артыграк – бренд.

Күләмле – киңлектәге композицияләрне урнаштыру рөхсәт ителми:

1) милек хуҗасыныкы, биләүченеке, файдаланучыныкы булган җир участогы, анда бина урнашкан һәм оешманың, шәхси эшмәкәрнең урнашу урыны, шулай ук аңардан файдалану яки туктау урыннары оештыру өчен бирелгән җир участогы чикләре янында;

2) аны декоратив бизәмичә генә нигезне тирәнәйтүнең техник мөмкинлеге булмаган очракларда;

3) гамәлдәге төзелеш, янгын сүндерү һәм санитар нормаларны һәм кагыйдәләрне исәпкә алып территорияләрне төзекләндерү буенча бинаның проект карары нигезеннән башка бер җир участогы чикләрендә бердән артыграк яисә башка аерым торучы мәгълүмат конструкциясе булганда;

4) төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектларын, мәдәният объектларын, Чистай шәһәре панорамаларын перспективаларын кабул итүне чикләүче;

5) шундый объект проектында каралмаган җир участогы чикләрендә бердән артык яисә аерым торучы башка мәгълүмат конструкциясе булганда;

6) шундый объект проектында каралмаган җир участогы чикләрендә бердән артык яисә аерым торучы башка мәгълүмат конструкциясе булганда;

7) Чистай шәһәренең тарихи территорияләре чикләрендә, эре сәүдә-административ биналар, корылмалар, шулай ук мәдәни-күңел ачу билгеләнешендәге объектлар (музейлар, концерт заллары, кинотеатрлар, күргәзмә комплекслары), гомуми мәйданы 5000,0 кв. м.дан артыграк булган спорт комплекслары, ягулык салу станцияләре урнашкан җир участокларында бер конструкция урнаштырудан кала;

8) конструкция нигезеннән бина нигезенә кадәр 6,0 м якын аралыгында;

9) тротуарларда һәм җәяүлеләр сукмагында, автомобильләр туктау өчен билгеләнгән урыннарда;

10) яшел үсентеләр (агачлар, куаклар) урынына;

11) агач кәүсәләреннән 5,0 м якын аралыгында эчкә төшкән нигез булганда;

12) ясаганда профнастилдан, тукыма материаллардан файдаланып;

13) мәгълүмат өслекләрен күренешләрне алмаштырып, шулай ук медиа-экраннар белән берлектә урнаштырып кечкенә форматта;

14) мәгълүмат кырында фоторәсемнәр белән;

15) гомуми мәйданы 5000,0 кв. метрдан азрак булган биналар өчен эре форматта, ягулык салу станцияләреннән кала;

16) мәгълүматны тапшыруның динамик ысулыннан файдаланып, ягулык салу станцияләренең ягулыкка бәя турындагы мәгълүмат белән медиа-экраннар, күләмле- киңлектәге композицияләрдән кала;

17) гомуми мәйданы 1500 кв.метрдан артыграк булган күпләп йөри торган биналар, корылмалар өчен, брендтан файдаланмыйча гына.

227.4.9. Щит конструкциясе – эчке һәм тышкы яктырту белән аерым торучы мәгълүмат конструкциясе, 4,0 мдан артык булмаган биеклектә, нигездән, каркастан, декоратив элементлардан, мәйданы 6,0 кв.м.дан артык булмаган ныклы нигездәге мәгълүмат кырыннан тора.

Щит конструкцияләрен урнаштыру рөхсәт ителми:

1) милек хуҗасыныкы, биләүченеке, файдаланучыныкы булган җир участогы, анда бина урнашкан һәм оешманың, шәхси эшмәкәрнең урнашу урыны, шулай ук аңардан файдалану яки туктау урыннары оештыру өчен бирелгән җир участогы чикләре янында;

2) аны декоратив бизәмичә генә нигезне тирәнәйтүнең техник мөмкинлеге булмаган очракларда;

3) гамәлдәге төзелеш, янгын сүндерү һәм санитар нормаларны һәм кагыйдәләрне исәпкә алып территорияләрне төзекләндерү буенча бинаның проект карары нигезеннән башка бер җир участогы чикләрендә бердән артыграк яисә башка аерым торучы мәгълүмат конструкциясе булганда;

4) төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектларын, мәдәният объектларын, Чистай шәһәре панорамаларын һәм перспективаларын кабул итүне чикләүче;

5) шундый объект проектында каралмаган җир участогы чикләрендә бердән артык яисә аерым торучы башка мәгълүмат конструкциясе булганда;

6) шундый объект проектында каралмаган җир участогы чикләрендә бердән артык яисә аерым торучы башка мәгълүмат конструкциясе булганда;

7) Чистай шәһәренең тарихи территорияләре чикләрендә, эре сәүдә-административ биналар, корылмалар, шулай ук мәдәни-күңел ачу билгеләнешендәге объектлар (музейлар, концерт заллары, кинотеатрлар, күргәзмә комплекслары), гомуми мәйданы 5000,0 кв. м.дан артыграк булган спорт комплекслары урнашкан җир участокларында бер конструкция урнаштырудан кала;

8) конструкция нигезеннән бина нигезенә кадәр 6,0 м якын аралыгында;

9) тротуарларда һәм җәяүлеләр сукмагында, автомобильләр туктау өчен билгеләнгән урыннарда;

10) яшел үсентеләр (агачлар, куаклар) урынына;

11) агач кәүсәләреннән 5,0 м якын аралыгында эчкә төшкән нигез булганда;

12) ясаганда профнастилдан, тукыма материаллардан файдаланып;

13) мәгълүмат конструкциясен декоратив-сәнгати бизәмичә генә;

14) гомуми кулланыштагы территория чикләрен билгеләүче кызыл линия белән чиктәш җир участогы чикләреннән 6,0 метрга якын арада;

15) мәгълүматны тапшыруның динамик ысулыннан файдаланып.

227.4.10. Әләмнәр композициясе - аерым торучы мәгълүмат конструкциясе, ул нигездән, бер яки берничә флагштоктан һәм йомшак полотнодан (мәгълүматлар кыры) тора.

Әләмнәр композициясе урнаштыру рөхсәт ителми:

1) милек хуҗасыныкы, биләүченеке, файдаланучыныкы булган җир участогы, анда бина урнашкан һәм оешманың, шәхси эшмәкәрнең урнашу урыны, шулай ук аңардан файдалану яки туктау урыннары оештыру өчен бирелгән җир участогы чикләре янында;

2) аны декоратив бизәмичә генә нигезне тирәнәйтүнең техник мөмкинлеге булмаган очракларда;

3) гамәлдәге төзелеш, янгын сүндерү һәм санитар нормаларны һәм кагыйдәләрне исәпкә алып территорияләрне төзекләндерү буенча бинаның проект карары нигезеннән башка бер җир участогы чикләрендә бердән артыграк яисә башка аерым торучы мәгълүмат конструкциясе булганда;

4) төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектларын, мәдәният объектларын, Чистай шәһәре панорамаларын һәм перспективаларын кабул итүне чикләүче;

5) шундый объект проектында каралмаган җир участогы чикләрендә бердән артык яисә аерым торучы башка мәгълүмат конструкциясе булганда;

6) шундый объект проектында каралмаган җир участогы чикләрендә бердән артык яисә аерым торучы башка мәгълүмат конструкциясе булганда;

7) Чистай шәһәренең тарихи территорияләре чикләрендә, эре сәүдә-административ биналар, корылмалар, шулай ук мәдәни-күңел ачу билгеләнешендәге объектлар (музейлар, концерт заллары, кинотеатрлар, күргәзмә комплекслары), гомуми мәйданы 5000,0 кв. м.дан артыграк булган спорт комплекслары урнашкан җир участокларында бер конструкция урнаштырудан кала;

8) конструкция нигезеннән бина нигезенә кадәр 6,0 м якын аралыгында;

9) тротуарларда һәм җәяүлеләр сукмагында, автомобильләр туктау өчен билгеләнгән урыннарда;

10) яшел үсентеләр (агачлар, куаклар) урынына;

11) агач кәүсәләреннән 5,0 м якын аралыгында эчкә төшкән нигез булганда;

12) мәгълүмат кыры габаритлары белән, флагштоклар арасындагы арадан зуррак киңлектә.

227.4.11. Махсус конструкция - аерым торучы мәгълүмат конструкциясе, ул халыкны яклау һәм иминлекне тәэмин итү өлкәсендәге социаль мөһим мәгълүматны, шулай ук спорт, мәдәни-масса-күләм чаралар турындагы мәгълүматны яшәүчеләргә белдерү өчен билгеләнгән, ул нигездән, каркастан тора, нейтраль төстәге материаль белән тышланган, электрон экран төрендәге мәгълүмат кыры, видеокүренешләрне күрсәтү мөмкинлеге бирә, җир участогы мәйданы 3 гектардан артыграк булган эре сәүдә һәм спорт,мәдәни-күңел ачу комплекслары җир участокларында урнаштырыла.

Махсус конструкцияләрне урнаштыру рөхсәт ителми:

1) милек хуҗасыныкы, биләүченеке, файдаланучыныкы булган җир участогы, анда бина урнашкан һәм оешманың, шәхси эшмәкәрнең урнашу

урыны, шулай ук аңардан файдалану яки туктау урыннары оештыру өчен бирелгән җир участогы чикләре янында;

2) аны декоратив бизәмичә генә нигезне тирәнәйтүнең техник мөмкинлеге булмаган очракларда;

3) гамәлдәге төзелеш, янгын сүндерү һәм санитар нормаларны һәм кагыйдәләрне исәпкә алып территорияләрне төзекләндерү буенча бинаның проект карары нигезеннән башка бер җир участогы чикләрендә бердән артыграк яисә башка аерым торучы мәгълүмат конструкциясе булганда;

4) төзелү датасы 1959 елга кадәр булган мәдәни мирас, тарихи биналар объектларын, мәдәният объектларын, Чистай шәһәре панорамаларын һәм перспективаларын кабул итүне чикләүче;

5) шундый объект проектында каралмаган җир участогы чикләрендә бердән артык яисә аерым торучы башка мәгълүмат конструкциясе булганда;

6) стационар булмаган сәүдә объекты, шәхси яки күп фатирлы торак йорт алып торган җир участогы чикләрендә;

7) Чистай шәһәренең тарихи территорияләре чикләрендә, эре сәүдә-административ биналар, корылмалар, шулай ук мәдәни-күңел ачу билгеләнешендәге объектлар (музейлар, концерт заллары, кинотеатрлар, күргәзмә комплекслары), гомуми мәйданы 5000,0 кв. м.дан артыграк булган спорт комплекслары урнашкан җир участокларында бер конструкция урнаштырудан кала;

8) конструкция нигезеннән бина нигезенә кадәр 6,0 м якын аралыгында;

9) тротуарларда һәм җәяүлеләр сукмагында, автомобильләр туктау өчен билгеләнгән урыннарда;

10) яшел үсентеләр (агачлар, куаклар) урынына;

11) агач кәүсәләреннән 5,0 м якын аралыгында эчкә төшкән нигез булганда;

12) ясаганда профнастилдан, тукыма материаллардан файдаланып.”;

2. Әлеге карар масса-күләм мәгълүмат чараларында рәсми бастырылган вакыттан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны масса-күләм мәгълүмат чараларында һәм “Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүмат порталын”да (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтындагы “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә www.chistopol.tatarstan.ru. бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә - О.В. Добронравовага йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д.А. Иванов

Чистай шәһәрен
төзекләндерү
Кагыйдәләренә
кушымта

БИНАЛАР ФАСАДЛАРЫНДА ТЫШКЫ МӘГЪЛҮМАТ ЧАРАЛАРЫН УРНАШТЫРУ ВАРИАНТЛАРЫ

ДИВАР КОНСТРУКЦИЯЛӘРЕН УРНАШТЫРУ

УРНАШТЫРУ ПРИНЦИПЛАРЫ ҺӘМ ВАРИАНТЛАРЫ

МӘДӘНИ МИРАС  ОБЪЕКТЛАРЫ ҺӘМ ТАРИХИ ОБЪЕКТЛАР



ТОРАК БИНАЛАР ҺӘМ ТОРАК БУЛМАГАН БИЛГЕЛӘНЕШТӘГЕ ОБЪЕКТЛАР







КОНСОЛЬЛЕ КОНСТРУКЦИЯЛӘРНЕ УРНАШТЫРУ

---

УРНАШТЫРУ ПРИНЦИБЫ ҺӘМ РӨХСӘТ ИТЕЛӘ ТОРГАН КҮЛӘМНӘР
ТОРАК БУЛМАГАН БИЛГЕЛӘНЕШТӘГЕ ОБЪЕКТЛАР



МӘДӘНИ МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫ ҺӘМ ТАРИХИ ОБЪЕКТЛАР




КОНСОЛЬЛЕ КОНСТРУКЦИЯЛӘРНЕ УРНАШТЫРУ РӨХСӘТ ИТЕЛМИ

---

ТОРАК БИНАЛАР ҺӘМ ӨСТӘП-ЯЛГАП ТӨЗЕЛГӘН БИНАЛАР




**Не допускается размещение консольных конструкций в пределах жилых помещений, непосредственно над входом в здание, а также на расстоянии менее 10м друг от друга**

МӘДӘНИ МИРАС  ОБЪЕКТЛАРЫ ҺӘМ ТАРИХИ ОБЪЕКТЛАР




**Не допускается размещение консольных конструкций выше 1-го этажа, непосредственно над входом в здание, а также на расстоянии менее 10м друг от друга**

ТҮБӘ КОНСТРУКЦИЯЛӘРЕН УРНАШТЫРУ

---

УРНАШТЫРУ ПРИНЦИБЫҺӘМ РӨХСӘТ ИТЕЛӘ ТОРГАН КҮЛӘМНӘР
ТОРАК БУЛМАГАН БИЛГЕЛӘНЕШТӘГЕ ОБЪЕКТЛАР







ТҮБӘ КОНСТРУКЦИЯЛӘРЕН УРНАШТЫРУ РӨХСӘТ ИТЕЛМИ

МӘДӘНИ МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫ ҺӘМ ТАРИХИ ОБЪЕКТЛАР




ТОРАК БИНАЛАР




ВИТРИНА КОНСТРУКЦИЯЛӘРЕ

УРНАШТЫРУ ПРИНЦИБЫ ҺӘМ РӨХСӘТ ИТЕЛӘ ТОРГАН КҮЛӘМНӘР







ТОРАК БУЛМАГАН БИЛГЕЛӘНЕШТӘГЕ БИНАЛАРДА МӘГЪЛҮМАТ КОНСТРУКЦИЯЛӘРЕН УРНАШТЫРУ

ДОПУСКАЕТСЯ




НЕ ДОПУСКАЕТСЯ

тип 1 - настенная конструкция:
1.1. - фоновая конструкция;
1.2. - бесфоновая конструкция;
1.3. - конструкция в виде световых коробов;
тип 2 - вывеска;
тип 3 - декоративное панно;
тип 4 - крышная установка.
тип 5 - консольная конструкция:
5.1. - модульная;
5.2. - малая;
тип 6 - витринная конструкция;
тип 7 - конструкция на ограждении




ТОРАК БИНАЛАРДА МӘГЪЛҮМАТ КОНСТРУКЦИЯЛӘРЕН УРНАШТЫРУ

ДОПУСКАЕТСЯ




тип 1 - настенная конструкция:
1.1. - фоновая конструкция;
1.2. - бесфоновая конструкция;
1.3. - конструкция в виде световых коробов;
тип 2 - вывеска;
тип 3 - декоративное панно;
тип 4 - крышная установка.
тип 5 - консольная конструкция:
5.1. - модульная;
5.2. - малая;
тип 6 - витринная конструкция;
тип 7 - конструкция на ограждении

НЕ ДОПУСКАЕТСЯ




МӘДӘНИ МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫНДА ҺӘМ ТАРИХИ ОБЪЕКТЛАРДА МӘГЪЛҮМАТ КОНСТРУКЦИЯЛӘРЕН УРНАШТЫРУ

ДОПУСКАЕТСЯ




тип 1 - настенная конструкция:
1.1. - фоновая конструкция;
1.2. - бесфоновая конструкция;
1.3. - конструкция в виде световых коробов;
тип 2 - вывеска;
тип 3 - декоративное панно;
тип 4 - крышная установка;
тип 5 - консольная конструкция:
5.1. - модульная;
5.2. - малая;
тип 6 - витринная конструкция;
тип 7 - конструкция на ограждении

НЕ ДОПУСКАЕТСЯ




КЕРҮ ФРИЗЫНДА ДИВАР КОНСТРУКЦИЯЛӘРЕН УРНАШТЫРУ РӨХСӘТ ИТЕЛӘ

ИШЕКЛӘР


НАСТЕННОЕ ПАННО
фриз
БУКВЫ И ЗНАКИ


Единая композиционная ось
БУКВЫ И ЗНАКИ
БУКВЫ И ЗНАКИ
фриз
БУКВЫ И ЗНАКИ
организация 1
организация 2